РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН

СОВЕТ СТАРОИКШУРМИНСКОГО СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ САБИНСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА

422066, Республика Татарстан, Сабинский район, с.Старая Икшурма, ул. Ленина, д.17
тел. (84362) 41-6-47

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ

САБА МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ ИСКЕ ИКШЕРМӘ АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ СОВЕТЫ

422066, Татарстан Республикасы, Саба районы, Иске Икшермә авылы, Ленин урамы, 17 йорт
тел. (84362) 41-6-47

e-mail: sik.sab@tatar.ru

РЕШЕНИЕ 23.09.2019 — КАРАР № 27

Татарстан Республикасы Саба муниципаль районы Иске Икшермә авыл җирлеге Советының “Татарстан Республикасы Саба муниципаль районы Иске Икшермә авыл җирлеге Советы Регламентын раслау турында” 23.12.2009 елгы № 30 карарына үзгәрешләр кертү турында

ТР Саба районы прокуратурасының 10.09.2019 елгы №02-01-20-19 хатына, Саба муниципаль районы Иске Икшермә авыл җирлеге Уставына туры китереп, Иске Икшермә авыл җирлеге Советы КАРАР ИТТЕ:

1. Татарстан Республикасы Саба муниципаль районы Иске Икшермә авыл җирлеге Советының 23.12.2009 елгы № 30 карары белән расланган Иске Икшермә авыл җирлеге Советы Регламентына түбәндәге үзгәрешне кертергә:

1.1 Регламентның 6 нчы бүлеген түбәндәге эчтәлекле 34.1 статья белән тулыландырырга:

“Статья 34.1:

1. Иске Икшермә авыл җирлеге башлыгы, район прокуроры, шулай ук Иске Икшермә авыл җирлеге Уставы, закончалык белән вәкаләтле вазыйфаи затлар, Советның ачык һәм ябык утырышларында катнашырга хокуклы.

2. Советның ачык утырышларында Иске Икшермә авыл җирлегендә яшәүчеләр һәм массакүләм мәгълүмат чаралары вәкилләре катнаша ала.

3. Совет тарафыннан аларның эшчәнлегенә караган сорауларны караганда, башкарма комитет эшчеләре ачык утырышларда катнашырга хокуклы.

4. Әгәр гомуми депутатларның күпчелеге тарафыннан хупланса, Совет җирле үзидарәнең вазыйфаи затларының утырышта катнашуын таләп итәргә хокуклы.

Катнашу турында таләп, утырышка кадәр еч кеннән дә соңга калмыйча, Совет утырышына чакырылучы вазыйфаи затка утырышның кене, вакыты, урыны, утырышка куелган сораулар турында Совет рәисе тарафыннан хәбәр ителергә тиеш.

5. Утырышны ачар алдыннан, Совет рәисе Совет депутатлары булып тормаучы, утырышта катнашучы затлар турында игълан итә.

6. Утырышка чакырылган һәм катнашучы затлар Совет эшенә тыкшынырга хокуклы түгел. (чыгыш ясарга, белдерү эшләргә, хуплау яки ризасызлык белдерергә)

7. Совет карары нигезендә, чакырылганнарга әлеге Регламент кысаларында чыгыш ясау өчен сүз бирелергә мөмкин.”

8. Әлеге карарны Татарстан Республикасы рәсми хокукый мәгълүмат порталында «Интернет» челтәрендә http://pravo.tatarstan.ru адресы буенча һәм Татарстан Республикасы Саба муниципаль районы Иске Икшермә авыл җирлеге рәсми сайтында http://saby.tatarstan.ru/rus/ shitsi адресы буенча һәм җирлекнең мәгълүмати стендларында бастырырга.

9. Карар рәсми бастырып чыгарган көннән үз көченә керә.

10. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны үз естемдә калдырам.

Иске Икшермә авыл җирлеге башлыгы: Н.Н.Нурмөхәммәтов